

ЧИГЕНЕРГӘ ОХШАГАН

Ковид госпитальләрендә ятак урыннарны киметәләр

> 2

ГОРУРЛЫК КӨЕ

Ветеран журналист 80ләп илнең гимнын татарчага тәрҗемә иткән

> 3

ВАКЫТЛЫ ЯРДӘМ

Укытучы Елена Хәлилуллинага белгәннәрен тормышта еш кулланырга туры килгән

> 3

ПЕЧӘН ИСЕ

Әтнә театры башкалардан кай ягы белән аерылып тора?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 178 (28760) | Сишәмбе | 7 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

БЕЛГӘННЕҢ ӨЕ ҖЫЛЫ БУЛА

Яшәргә өйрәнәбез

Нәрсә килә – шуны түлибез. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен килгән квитанциягә игътибар белән укып утыручылар бармы икән? Дөресен әйткәндә, күп түгел. Әле тикшерә башласаң, аңларга да кирәк. «Белемле кулланучы мәктәбе»ндә һәр кешегә кагылган әнә шул сорауларга җавап табарга өйрәтәләр. Түләгән һәр сумның кая киткәне белән кызыксынучылар арта бара: җиде елда 20 меңнән артык кеше укып чыккан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанның Глушко урамында яшәүче Мәдинә Яппарованың да укыганы файдага булган.

– Торак-коммуналь хуҗалык буенча сорауларым бик күп җыелган иде. Аларны үзебезгә хезмәт күрсәтүче идарәче оешмага җиткердем. Берсенә дә төгәл җавап ала алмадым. Аптырагач, Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәгенә бардым. Андагылар минем һәр соравыма җавап бирде. Ул гына да түгел, махсус укуга язылдым. Алган белемем бушка китмәде, мин фатирым өчен җылылыкның ничек исәпләнгәнен, аның дөресме-юкмы икәнен беләм хәзер, – ди ул. – Яз көне урамда таеп егылып, билемне авырттырдым. Шул чакта үзәкнең юристлары ярдәм итте. Иренмәскә генә кирәк. ТКХ өлкәсендә көн саен белем арттырып торсаң да таман гына.

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә кагылышлы сораулар турында «Бердәм Россия» партиясенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә узган туры эфир барышында сөйләштеләр. «Узган ел белән чагыштырганда, 2021 елда безгә зарланып мөрәҗәгать итүчеләр саны 30 процентка кимеде. Халык үзенә хезмәт күрсәтүче идарәче оешмага барып, сорауларына җавап алырга хокуклы. Ике арада элемтә булырга тиеш. Шулай иткәндә, күп кенә сораулар тизрәк хәл ителер иде, – ди Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов. – Кызганыч, халык теге яки бу мәсьәлә белән үзенә кагылган очракта гына кызыксына башлый. Ә башка вакытта җыелышларга йөрмиләр, ниндидер карар кабул ителгәндә читтә калалар».

Дмитрий Романов әйтүенчә, халыктан килгән зарлар арасында иң еш очраганы квитанциядә язылган суммаларга бәйле. Күршеләр арасында «Безнең ишегалды» программасы буенча каршылыклар килеп чыккалый икән. Кемгәдер спорт мәйданчыгы кирәк, кемдер машина кую урыны сорый. Әнә шулай уртак фикергә килә алмаучылар да үзәккә мөрәҗәгать итә икән.

– Чүп чыгару проблемасы да күпләрне борчый. Кайдадыр контейнерлар җитми, кайсыдыр урында алар дөрес итеп куелмаган. Үз йортлары янында чүп ташлау урыны булмагач, күрше йорттагысына китереп куялар. Бер кешенең берничә фатиры, йорты булып, һәрберсе өчен акча түләтүдән дә зарланалар. Кеше авылдагы йортына җәй көне генә кайтып йөрергә мөмкин. Әмма бар кешегә дә таләп бер: күпме торагы бар, шуның кадәр түли.

Шулай ук капиталь төзекләндерү буенча да сораулар күп килә икән. Быел күп кенә йортларда ремонт эшләре кинәт туктатылган. Халык ничә ел көткән ремонт булмас дип борчыла. Ә урынга барып тикшергәч, эшләрнең төзелеш материалларына бәя арту сәбәпле туктап торганлыгы ачыкланган.

– Халыкка игътибарлы булырга кирәк. Күпләр идарәче оешма үткәргән җыелышларда катнашмый. Түләү квитанциясенә ниндидер яңа хезмәтне өстәү өчен, бу хакта милекчеләргә әйтергә, аларның 51 проценты ризалык бирергә тиеш. Нинди генә хезмәт күрсәтелсә дә, милекче бу хакта белергә тиеш. Сүз белән генә булмый. Мөрәҗәгатьләрне язып тапшырыгыз, – ди ул.

Очрашуда фатирлардагы газ плитәләре, казаннары хакында да сөйләштеләр. Дмитрий Романов әйтүенчә, халык газ оешмасыннан килүчеләрне кертергә атлыгып тормый икән. Кемдер, мошенниклар дип кертми, кемдер ишеген махсус ачмый.

– Фатирларга тикшерүчеләр киләсе алдан хәбәр ителергә тиеш. Алар таныклыгын күрсәтеп керә ала. Кертмим дигән кеше башкаларны куркыныч астына куя. Шуны да онытмаска кирәк. Күрше фатирда ниләр булып ятканын, кем яшәгәнен белмибез бит. Пластик тәрәзәләр кую да эшне катлауландыра. Газ белән агулану, шартлау җилләткечләр эшләмәүдән килеп чыга. Шуңа да аш бүлмәсендәге тәрәзәне бераз ачып куярга кирәк, – ди ул.

Дмитрий Романов су басса, түбәдән кар ишелеп зыян килсә нишләргә икәнен дә аңлатты. Моның өчен идарәче оешма, милекчеләр ширкәте җитәкчесен чакырырга кирәк. Әгәр алар килми икән, ике күршене шаһит итеп, акт төзисең. Шуннан соң үз дәгъваңны тиешле урынга җиткерәсең.

Җитәкче шулай ук үз белдегең белән балкон тышларга һәм аны пыяла белән капларга ярамавын да искәртте.

– 2022 елның 2 мартыннан моның өчен штраф сала башлаячаклар. Моңарчы тәрәзәсе булмаган балконнарга кагыла бу. Балкон тышлау өчен, тәрәзә куяр өчен, аны алдан махсус комиссия тикшерергә тиеш. Алар рөхсәт биргән очракта гына, нидер үзгәртеп булачак. Әгәр үз белдегең белән эшлисең икән – 5 мең сум күләмендә штраф салачаклар. Бик күпләр, бүлмәләрне зурайтам дип, диварны җимерә. Йортта яшәүчеләрнең барысының да ризалыгын алмаган килеш, дивар күчерү дә ярамый. Әле шушы көннәрдә генә бер милекченең фатир үзгәртүен белеп алган идарәче оешма диварны кире үз урынына куйдыртты, – ди Дмитрий Романов.

Капиталь ремонт өчен җыелган акчаның кая киткәнен ничек белеп булуын да сорадылар. Моның өчен сезгә хезмәт күрсәткән оешмага язмача мөрәҗәгать итәргә кирәк икән. Җавап бирмәсәләр, торак инспекциясенә хәбәр итәргә була. Дмитрий Романов: «Киләчәктә ТКХ өлкәсендә дә акчаларның кая киткәнлеге, нинди эшләр башкарылганлыгы аермачык күренәчәк», – ди. Киләсе Цифрлаштыру елына өметләнә ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

30 укытучы белем бирә алмаячак

Татарстанда коронавируска каршы вакцинация узмаган 30 укытучы эштән читләштерелгән. Бу хакта Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин Instagram социаль челтәрендә оештырылган туры эфир вакытында хәбәр итте.

«Мәҗбүри вакцинация турында карар бар. Ә мәктәп хезмәткәрләре балалар белән эшли. Мәгариф системасы тәртип, чисталык, намуслылык һәм ачыклыкны ярата. Шуңа күрә үзеңә һәм мәктәп администрациясенә проблема ясамыйча, озакка сузмыйча вакцинация узуыгызны сорыйм», – диде министр.

Узган тәүлектә Татарстанда тагын 227 кешедә коронавирус табылды. Республикада 2089913 кеше (бер тәүлеккә үсеш – 18189) коронавируска каршы вакцина ясаткан. Шуларның 1646923е прививканың икенче дозасын кадаткан.

Сүз уңаеннан, Россиядә коронавирусның «омикрон» штаммы барлыгы да расланган. Аны Көньяк Африка Республикасыннан кайткан ике кешедә ачыклаганнар. Бу хакта Роспотребнадзор идарәсенең матбугат хезмәте хәбәр итә.

Саклык акча күләме арткан

1 ноябрьгә алынган мәгълүматларга караганда, республикада яшәүчеләр банкларда 703,4 миллиард сум күләмендә акча (торак төзү өчен эскроу-счетларга салынганын да кертеп) саклый. Бер ел эчендә саклык акча күләме 7,1 процентка арткан. Халык, элеккечә, үзебезнең рубльне салуга өстенлек бирә. Рубль өлеше банкка салынган барлык акча күләменең 86,2 процентын (606,4 миллиард сум, бер ел эчендә 9,3 процентка арткан) тәшкил итә. Чит ил валютасындагы саклык акчасы исә бер ел эчендә 4,7 процентка кимеп, 97,0 миллиард сумга калган.

Банкка акча салу – элеккечә үк, акча саклауның иң уңайлы ысулы. Банкның лицензиясе алынса, депозит хуҗасына 1,4 миллион сумга, кайбер очракларда 10 миллион сумга кадәр кире кайтарыла. Россия банкының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин әйтүенчә, банкка акча салучыларны процент ставкаларының үсүе кызыктыра.

Ярминкә дәвам итә

kzn.ru

Татарстанда көзге ярминкәләр дәвам итә. Биредә шәһәрләр өчен ит, сөт һәм сөт ризыклары, йомырка, яшелчә, бал, шикәр кебек азык-төлекне арзанрак бәядән сатып алу мөмкинлеге бар. Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, 11 сентябрьдән ярминкәләрдә 5313 тонна бәрәңге, 2438 тонна суган, 2 млн данәдән артык йомырка сатылган.

Сатылган товарлар бәясе 1 млрд сумнан артып китә. «Хәзерге вакытта ярминкәләрдә продукциягә кытлык юк, шәһәр халкы кирәкле азык-төлек белән тулысынча тәэмин ителә», – дип хәбәр итә матбугат үзәге. Исегезгә төшерәбез: ярминкәләр 25 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Салкын озакка килмәде

Татарстанга антициклон үтеп керү сәбәпле, суытты, аязды. Әмма атна уртасында һава торышы янә үзгәрә. Гидрометеоүзәк фаразларына караганда, чәршәмбе көнне иртән һәм көндез яңгыр, юеш кар, секундына 15–17 метрга кадәр тизлектә җил, юлларда урыны белән көчле бозлавык көтелә. Һава температурасы көндез –4...+1 градус, төнлә 15 градуска кадәр суык. Пәнҗешәмбе көнне дә җылы: көндез 0–4, төнлә –1...–6 градус.

Җомга һәм шимбәдә көндез һава температурасы 0–4 градус, төнлә –2...–7 градус аралыгында саклана, урыны белән аз гына кар фаразлана.

Көн кадагында

Вакцина хаҗга юл ача

Согуд Гарәбстаны «Спутник V» вакцинасын ясаткан кешеләргә хаҗ кылуны рөхсәт итте. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның гарәп иленә сәяхәтеннән соң илнең Сәламәтлек саклау министрлыгы шундый карар кабул иткән.

«1 гыйнвардан «Спутник V»ның ике дозасын да ясатканнарга илгә кыска вакытка килү рөхсәт ителә. Бу рөхсәт, шул исәптән, гомрә һәм хаҗ сәфәре кылуга да кагыла», – диелә министрлык хәбәрендә. Вакцина ясаткан хаҗилар Согуд Гарәбстанына килгәннән соң, 48 сәгать карантинда булырга һәм ПЦР-тест бирергә тиеш булачак.

Билгеле булганча, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күптән түгел Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул илнең хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министр урынбасары Габделфәттах бән Сөләйман Машат белән дә очрашты. Татарстан Президенты аннан хаҗ кылырга теләгән мөселманнар өчен чикләрне ачуны сорады. «Кәгъбәне күрү, Мәккәдә булу – безнең өчен зур бәхет. Гомрә кылганда, безнең илдән бик күпләрнең хаҗ кылырга теләгәне турында уйладым. Шуңа күрә сездән аларга мондый мөмкинлек бирүне сорамый булдыра алмыйм. Вакцина ясатып, кулына шул хакта документ алган кешеләр бар. Россиядә җитештерелгән «Спутник V» вакцинасы яхшы, әлегә ул Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасында теркәлмәгән, бу юнәлештә эш бара. Вакцина ясаткан Россия хаҗиларын кертүләрен үтенеп, алдан ук килешеп куясыбыз килә», – диде Президент очрашуда.

Министр урынбасары исә, үз чиратында, бу мәсьәләне җентекләп тикшерергә вәгъдә бирде.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хаҗ» оешмасы генераль директоры Ранис хәзрәт Вахитов сүзләренә караганда, әлегә алар бу хәбәрнең расланганын көтә. «Бу мәсьәлә якын арада хәл ителер, хаҗиларыбыз, тынычлап, хаҗ сәфәренә бара алыр дип өметләнәбез», – ди ул. Ранис хәзрәт сүзләренә караганда, соңгы ике елда хаҗга барып булмагач, бу хәбәрне ишеткәч, кызыксынып шалтыратучылар, хаҗга барырга теләк белдерүчеләр күп булган. Алдагы елларда Татарстаннан 1800ләп кеше хаҗ кыла иде. Билгеле сәбәпләр аркасында хаҗга бара алмаган кешеләргә юллама акчалары кире кайтарылган. Быел җәй Согуд Гарәбстаны хакимияте корольлектә яшәүче 60 мең кешегә генә хаҗ кылырга рөхсәт иткән иде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Сергей НОВИКОВ, Россия Президенты администрациясенең иҗтимагый проектлар буенча идарә башлыгы:

Антиваксерлар, вакцина башта үзен акласын, дигән фикерләрен җиткерә, ә ул арада көн саен меңләгән кеше үлә тора. Бу – демократия, үз фикереңне ирекле чагылдыру дип санала. Алай түгел, бу халыкны юк итү стратегиясе һәм без моны белергә тиеш.

(«Без срока давности» илкүләм семинарында чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТ ЯШӘҮЧЕЛӘР

Россиядә сәламәт яшәү рәвешен алып баручылар Төньяк Кавказ Республикаларында яши икән. Хакасия, Сахалин, Камчатка кебек төбәкләрдә яшәүче халык, киресенчә, начар гадәтләрдән баш тартырга ашыкмый. «РИА Новости» агентлыгы илнең төрле төбәкләрендә гомер итүчеләрнең начар гадәтләргә бәйлелеген тикшергән. Белгечләр исемлекне төзегәндә теге яки бу төбәктә яшәүче халыкның тәмәке, хәмер һәм наркотикка мөнәсәбәтен исәпкә алган.

1	Чечен Республикасы
2	Дагыстан Республикасы
3	Ингушетия Республикасы
30	**Татарстан**
84	Камчатка
85	Хакасия

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙЧА ДЕМОГРАФИК КРИЗИС

Үткән атнада сәясәтчеләр һәм галимнәр «омикрон» штаммының куркынычлылык дәрәҗәсен ачыклау белән мавыктылар. «Үтә куркыныч» һәм «зыянсыз диярлек» дигән ике капма-каршы фикер үлчәү тәлинкәсендә тигезләште диярлек. Әмма бизнес һәм икътисад соңгы карашка ныграк ышана. Бу ОПЕК+ илләренең «кара алтын» чыгаруны арттырырга килешүләрендә дә күренә. Нефть бәясенең чагыштырмача түбәнгә китүе шуңа бәйле. Коронавирусны нәтиҗәле дәвалый торган дарулар турында хәбәрләр ешрак күренә. Пандемия 2026 елга кадәр барачак, дип куркытучылар булса да, өметләник: 2022 ел бу юнәлештә иминрәк булыр кебек.

Әмма дөньякүләм киеренкелек кимеми. Россиянең көнбатыш чигендә зур фаҗиганең прелюдиясен уйнарга теләгән көчләр активлаша. 7 декабрьдә Байден белән Путинның видеоэлемтә аша сөйләшүләре көтелә. Вашингтонда, Россия Украинага каршы сугыш башларга тели, дигән авазлар бик көчле яңгырый. Европалыларны да шуңа ышандырырга тырышалар. Көнбатыштан Киевка корал агыла, НАТО гаскәрләре дә потенциаль конфликт зонасында туплануларын көчәйтәләр. Төркия Украинага байрактарларның яңа зур партиясен озатырга әзерләнә. Путинның Украинаны Россия – НАТО мөнәсәбәтләрендәге кызыл сызык дип атавы сугыш карчыгаларын ярсытты гына. Алар Байден тавышы белән бернинди дә «кызыл сызыклар»ны танымауларын игълан иттеләр.

Хәрби киеренкелек һәм сугыштан башка да планетада проблемалар баштан ашкан. Иң күп халык яшәүче ил – Кытай демографик упкын чигенә якынлаша. 2020 елда анда туучылар саны Россиядәгедән дә азрак булган. Алар 2015 елда «бер гаилә – бер бала» сәясәтеннән баш тартты. Гаиләләргә кимендә өч бала табып үстерү максат итеп куелды. Хәзер өч баласы булмаган гаиләләргә санкцияләр кертергә телиләр. Шуңа карамастан да, туу коэффициенты түбән кала. Кытай Халык Республикасының Статистика буенча милли бюросы үткән елда 1978 елдан башлап илдә туу дәрәҗәсе рекордлы дәрәҗәдә түбән булу турында белдерде. Бер мең кешегә бары тик 8,52 генә яңа туган бала туры килгән. Чагыштырыйк: Россия күрсәткече – 9,8. Кытайда үлүчеләр саны артмый ләкин. Мең кешегә җидедән аз гына югарырак үлем күрсәткече теркәлгән. Шул сәбәпле халык саны 1,45 процентка арткан. Тик бу – алар өчен бик түбән күрсәткеч. Алдагы унъеллыкта кытайлылар бер елга 5,5 процентлык темп белән үрчегәннәр. Арту темпының түбәнәюе озакламый илнең минуслы күрсәткечкә чыгу ихтималлыгы зур булуына ишарә итә.

Статистика тагын бер нәрсәгә игътибарны юнәлтә: илдә үткән ел никахлар саны кискен кимегән. Гаилә корган яшьләр дә бала табарга теләмиләр, чөнки торак кыйммәт, балага белем бирү дә кыйбатка чыга, медицина ярдәме өчен дә акча табу кыен. Аерылышулар саны да кискен арткан. Нәтиҗәдә демографик кризис ил халкының өлкәнәюенә китереп, пенсия түләүдә кыенлыклар тудырырга вәгъдә итә.

Россиядә

МИЛЛИ БАЙЛЫК ФОНДЫН КЕМГӘ БИРЕРГӘ?

Пандемия һәм бәяләрнең кушаяклап сикерүе фонында Росстат күңелне күтәрә торган гаҗәеп фактлар ачыклый. Бердән, илдә фәкыйрьләр саны кискен кимегән. 3 миллионга якын россияле быелның өченче кварталында фәкыйрьләр исемлеген ташлап чыккан. Юк, бу алар матди яктан яхшырак яши башлаган дигән сүз түгел. Керемнәр кими, бәяләр арта. Болар – факт һәм ул факттан беркая да качып булмый. Безнең кесәләрдәге акчаны санаучы чиновниклар гына санау методикасын үзгәрткәннәр. Башкача саный башлагач, саннар болайрак чыккан: ел башында, ягъни беренче кварталда 20,8 миллион россияле ач дип табылган. Бу – барлык халыкның 14,2 проценты. Икенче кварталда очын очка ялгап яшәүчеләр саны 18,2 миллион кешегә калган. Процентка күчергәч – 12,5. Өченче кварталда инде 16 миллион кеше генә фәкыйрьлек чигендә дип табылган. Саннарның кимүенә «фәкыйрьлек чиге» дигән төшенчә кертү дә булышкан һәм, чиновниклар әйтүенчә, илдә кереме арткан кешеләр саны да ишәйгән. Аннан соң «Президент түләүләре» дигән күктән төшкән акча да булды бит инде сентябрьдә. Менә шулар да байтак россиялене фәкыйрьлек чигеннән муллык чигенә китергән. Аннан соң Росстат керемнәрнең артуын гына санаган.

Бюджет чүпрәсе шулкадәр кабара: Салым федераль хезмәте җитәкчесе Даниил Егоров быел салымнарның 7 триллион сумга күбрәк җыелачагын әйтә. Бик зур сумма инде. Әмма бездә «бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй» дигән принцип белән яшәмиләр бюджет төзүчеләр. Аз гына артык акча кердеме, аны шунда ук Милли байлык фондының капчыгына салып, кысып бәйләп куялар. Икътисадчы галимнәр бу капчыкны чишеп, акчасын үсеш максатларында тотарга өндәп карасалар да, билгеле бер критерийлар бар, акча күләме шул критерийлардан арткач кына аны төрле проектларга бүлә башлыйлар. Милли байлык фондыннан 2024 елга кадәр 2,5 триллион сумны инвестицияләргә тотып булачак икән. Финанс министрлыгы «Шул акчаларны нинди проектларга тотарга?» дигән сорауга җавап әзерли. Икътисади үсеш министрлыгында инде проектлар исемлегенең Президент белән килештерелгәнен әйтәләр. 12 проект күз алдында тотыла: сәнәгать һәм инфраструктураны үстерү, тимер юллар һәм автомобиль юллары төзү (М12 Мәскәү – Казан трассасы да шул исемлектә тора), ТКХ тармагын модернизацияләү. Акча агымын үзләре теләгән уңайга борырга теләүче чиновниклар күп икән. Проектлар саны да бихисап. Әмма Икътисади үсеш министрлыгы җитәкчесе Решетников әфәнде күп проектларның иләк аша үтмәүләрен әйтә, чөнки чиновниклар күрәләтә зыянлы тәкъдимнәр белән киләләр, хәтта үз эшчәнлекләре нәтиҗәсендә салынган зыянны Милли байлык фондыннан каплатырга теләүчеләр дә бар.

ПАРТИЯГӘ ЭШ ҖИТӘРЛЕК

Мәскәүдә «Бердәм Россия»нең 20 нче – юбилей съезды узды. Узган сайлауга йомгак ясадылар, партиянең җитәкче органнары яңартылды. Дмитрий Медведев алга таба да партия рәисе вазыйфасын башкарачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Югары Совет составына керде.

Россия Президенты Владимир Путин съездда катнашучыларга видеоэлемтә аша мөрәҗәгать итте. Аның әйтүенчә, «Бердәм Россия» сайлауны уңышлы уздырган. «Сез халыкны җәлеп итү өчен «кычкырып торган» купшы лозунглар белән эш итмәдегез. Алар бит гадәттә буш вәгъдәләргә генә әйләнеп калучан. Сез сайлаучылар белән башкача эшләдегез», – диде Путин. Ул «Бердәм Россия» программасының, кешеләр белән очрашып, аларны иң нык борчыган мәсьәләләр буенча аралашулар нәтиҗәсендә булдырылуын искә төшерде. «Аның һәрбер пункты төптән уйланылган, куелган бурычларны үтәүнең төгәл вакытлары билгеләнгән», – диде ул. Путин әйтүенчә, кешеләр юкка гына, иң дәрәҗәле сәяси көч ярдәменә исәп тотып, бердәмроссиялеләргә мөрәҗәгать итми. Чөнки партия кешеләрне борчыган мәсьәләләрне хәл кылу өчен барлык мөмкинлекләргә ия. Шул ук вакытта Президент «Бердәм Россия»гә, бер бурычны үтәүгә үк, икенчесен куярга, дигән принципны истә тотарга тәкъдим итте. Ул партияне 20 еллык юбилее белән котлап, аны ышанычлы, куәтле сәяси көч буларак санавын әйтте. Путин шушы еллар эчендә «Бердәм Россия»нең иң кирәкле вакытларда ил өчен җаваплылыкны үз өстенә алу осталыгын раслап килүен искә төшерде.

«Бердәм Россия» рәисе Дмитрий Медведев соңгы биш ел эчендәге эш йомгакларына кагылып, партиянең, кыенлыкларга карамастан, 2016 елгы сайлау алды программасында күрсәтелгән барлык бурычларын диярлек үтәве турында сөйләде. Халык программасын һәм Россиянең үсеше өчен планнарны тормышка ашыру өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек. «Көч тә, 20 еллык тәҗрибә һәм белем дә бар. Тәҗрибәле һәм сыналган кадрлар бар. Президентның ярдәме бар. Башкарма хакимият, белгечләр, җәмәгатьчелек, бизнес белән тыгыз элемтәләр бар. Иң мөһиме – абруй һәм илнең һәр төбәгендә йогынты бар», – диде ул. Аның әйтүенчә, «Бердәм Россия» пандемиянең аянычлы нәтиҗәләрен юкка чыгару эшен күпме кирәк – шул вакыт дәвамында алып барачак. «Депутатларыбызга, волонтерларга өстәмә бурыч – ничек тә күбрәк кешеләргә вакцинациянең мөһимлеген аңлату бурычы төшә», – диде ул.

Съездда катнашучылар Дмитрий Медведевны алдагы биш елга партия рәисе итеп яңадан сайлады. Борис Грызлов партиянең Югары Советы рәисе булып калды. Сүз уңаеннан, Югары Советның составы яртылаш диярлек яңартылган. Съездда республикадан 21 кеше катнашты. Алар арасында – Дәүләт Думасы, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, партиянең җирле бүлекләре активистлары.

ЧИГЕНЕРГӘ ОХШАГАН

КОВИД ГОСПИТАЛЬЛӘРЕНДӘ ЯТАК УРЫННАРНЫ КИМЕТӘЛӘР

Көн кадагында

Республиканың ковид госпитальләрендә ятак урыннар санын киметә башлаганнар. Соңгы арада республикада коронавирус белән авыручылар санының кимүе күзәтелә. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков хәбәр итте.

Министр моны коронавируска каршы кертелгән чикләүләр, чиргә каршы күпләп вакцина ясату нәтиҗәсе дип бәяли. «Госпитальләрдә барлыгы 7 меңләп ятак урын әзерләнгән иде. Хәзерге вакытта шуларның 1 меңгә якыны сүтелде. Әле узган атнада гына барлыгы 500 урын бушады. Коронавирус белән авыручылар саны кими», – ди министр. Шулай да күкрәк киереп җиңел суларга иртәрәк әле, билгеле. Белгечләр ике атнада ковид белән бәйле вазгыятьне җентекләп күзәтергә җыена.

– Чикләүләрдән башка гына мондый күрсәткечләргә ирешеп булмый. Эпидемия чорында чикләүләр кертелү – гадәти күренеш. Ул шулай булган һәм булачак. Бу яңалык түгел. Әмма бездә моңа күпләр никтер тискәре карый. Вакцина ясатасы килмәгән кешене беркем дә мәҗбүр итми. Ул ирекле. Советлар Союзы вакытында ул яктан җиңелрәк иде, мондый каршылыклар килеп чыкмады. Вакцинация календаре буенча һәркем, тыныч кына барып, прививка ясатып кайта иде, – дип сөйләде Марат Садыйков матбугат очрашуында.

Министр 81 яшьлек әтисе белән 76 яшьлек апасының да коронавируска каршы прививка ясатканлыгын искәртте. Ул гына да түгел, ярты елдан Садыйковлар гаиләсе ревакцинация дә узарга өлгергән инде. «Башка юл юк. Вакцинага салкын карау аркасында кызамык чире кире әйләнеп кайтты. Аннан да яманрак чәчәк һәм чума авырулары да яңадан пәйда булса, бик кызганыч булачак. Үз вакытында алар да бик зур югалтулар белән, бик зур фаҗига рәвешендә узды», – ди министр. Табигатьтәге үзгәрешләр кебек үк, тарихтагы пандемияләр дә кабатланып тора. Йөз ел элек – 1920 елда испанка (грипп авыруы төре) котырган булса, 50 елдан – гонконг гриппы, 2020 елда коронавирус «һөҗүм» итте.

Министр сүзләренә караганда, Татарстанда вакцинага кытлык юк. Хәзерге вакытта республикада коронавируска каршы 600 мең доза вакцина бар, шуларның 80 процентын

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Спутник V» тәшкил итә. Алдагы өч айда Татарстанга ковидка каршы борынга сала торган (назаль) вакцина да кайтартылачак. Ул гамәлдәге вакциналарга алмашка түгел, аларга өстәлмә рәвешендә кулланылачак. Хәтерләсәгез, әле бу көннәрдә генә Гамалея исемендәге эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү үзәге башлыгы Александр Гинцбург, назаль вакцина тулысынча зарарсыз, дигән белдерү белән чыгыш ясаган иде. Галим сүзләренә караганда, әлеге яңа төр вакцинаны кечкенә балалар да җиңел кичергән.

Назаль вакцинаны сынауда Россия Президенты Владимир Путин да катнашты. Ил башлыгы, прививка ясатып алты ай узгач, организмында антитәнчекләр күләме кимүен, шуңа күрә ревакцинация ясарга карар кылуын белдергән. Президент сүзләренә караганда, табиб сыеклык урынына шприцка порошок җыйган, тирән итеп сулыш алуын сораган һәм чиратлаштырып борын эченә вакцина керткән. Соңыннан Путин 15 минут утырып торган һәм бу процедура тәмамланган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Алмаска да, бирмәскә дә өйрәтәләр

Яшьләрнең «гаделлек», «намус» дигән төшенчәләргә ихтыяҗы зуррак. Шуңа да алар белән ришвәтчелек хакында сөйләшү кирәк тә, нәтиҗәлерәк тә. Ришвәтчеләрне тоту – хокук сакчылары эше булса, ришвәтчелекне булдырмау – гадел яшьләр җилкәсендә. Ә яшьләрнең тәэсир итү кораллары төрле.

Яшьләр телен үзләре кебекләр яхшырак аңлый, билгеле. Татарстан Президентының Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов әйтүенчә, яшь буын үзләре белем алган уку йортларында, район җирлекләрендә яшьтәшләренә аңлату эшләре алып баруда катнаша.

– Ришвәтчелекне булдырмый калу чараларын оештыру бик мөһим. Хәзерге вакытта Татарстанда коррупциягә каршы 26 студент комиссиясе эшләп килә. Районнарда ришвәтчелеккә каршы вәкилләрнең ярдәмчеләре бар. Аларның саны – 16, – диде Президент киңәшчесе. – Ел нәтиҗәләрен карасак, 10 меңләп яшь буын вәкилен җәлеп иткән төрле чаралар оештырылган. Шунысы да бар: яшьләргә ришвәтчелек темасын эчтән өйрәнү аеруча кызык. Бу җәһәттән узган елдан башлап Казан федераль университеты базасында «Коррупциягә каршы эшчәнлек» юнәлеше буенча магистрлар укыту мөмкин булды.

Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева әйтүенчә, яшьләрне җәмгыятьтә барган төрле процессларга җәлеп итү – нәтиҗәле һәм мөһим алым. Ришвәтчелеккә каршы эшчәнлек тә искәрмә түгел.

– Хокукый белем алучы яшьләребез өчен бу практик яктан да әһәмиятле. Әйткәнебезчә, яшьләргә бу тема кызык, чөнки ул гаделлек, намус, дөреслек турында искә төшерә. Барлык чараларда да без гаделлек хисен тәрбияләү турында сөйләшәбез, – диде ул.

Мәгълүм булганча, 9 декабрьдә Казан Коррупциягә каршы бөтенроссия яшьләр форумын кабул итәчәк. Чарада Мурманск, Воронеж, Ульяновск өлкәләреннән һәм Татарстаннан 250 кеше катнашыр дип көтелә. Форум кысасында яшьләр ришвәтчелекне кисәтү һәм аңа каршы көрәшүнең яңа алымнарын эзләү максатыннан оештырыла.

– Көзен без югары уку йортларында булдык, студентлар белән аралаштык, алар борчыган проблемалары турында сөйләде. Быел форум кызыклы булырга охшаган. IT-паркта узачак чарага Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков, Иннополис мэры Руслан Шагалиев, «Урам» экстрим-паркы җитәкчесе Мария Крюкова кебек шәхесләр чакырулы, – дип сөйләде «Не дать – не взять!» коррупциягә каршы республикакүләм яшьләр программасы җитәкчесе Алена Лапенкова. Өстәмә рәвештә яшьләрнең коррупциягә каршы проектлар лабораториясе дә узачак. Иң яхшы эшләрне акчалата бүләкләр көтә. Бу – 20–40 мең сум күләмдә грант.

Мондый форумнардан файда бармы?

– Мондый чаралар күбрәк профилактик алым булып тора. Ришвәтчелекнең тискәре якларын күрсәтү, тәрбия бирү – форумнарның максаты шул. Әйтик, яшь буын вәкиле: «Минем әти-әнием фәлән-фәлән түрә түгел, мин дә яхшы эш таба алмам инде», – дип уйларга мөмкин. Без исә: «Син тырыш булсаң, хезмәт ятратсаң, яхшы укысаң, уңай нәтиҗәләргә ирешерсең», – дип, мисаллар китереп, фикерләрен үзгәртәбез, – дип аңлатты Салават Рәхимов.

КАЗАН ЭШМӘКӘРЕ РАФАЭЛЬ ГЫЙМАЗОВ:

«АВЫЛДА БИЗНЕС АЧУЫМА ШАТЛАНАМ»

Татарстанда җитештерелгән

Балык Бистәсе районында елына 160 тонна балык үстерелү, шуның күп өлеше эшкәртелеп, кибетләргә 20 төрле балык продукциясе чыгарылу – бер хәл. «Клариус» җәмгыяте африка җәене дип аталучы балык үрчетә башлаган. Безнең якларда сирәк үрчетелүче форель, чөгә һәм башка төр балык маймычлары җибәреп, елына 150 тонна балык ите һәм 2000 килограмм уылдык җитештерәләр.

Районда бүген авыл хуҗалыгының төрле юнәлешләрендә яңадан-яңа җитештерүчеләр барлыкка килә. Николай Володин җитәкчелегендәге крестьян-фермер хуҗалыгында 100 гектар мәйданда кура җиләге, карлыган, крыжовник, сырганак һәм башка төрле җиләк-җимеш эшкәртү, «Каз» хуҗалыгында меңнәрчә баш каз, үрдәк, мисыр тавыгы һәм башка төр кош-корт үстерү, «Масловка» кооперативында ел әйләнәсе яшелчә, Күгәрчен авылында мәрмәр иттән 46 төрле продукция җитештерү – болар барысы да яңа эш урыннары булдыруга этәргеч биргән. Ә эш урыннары булган авылның киләчәге дә өметле.

– Бүген авыл хуҗалыгында дөньяның иң алга киткән илләре үрнәгендә заманча техника һәм технологияләрдән башка үсеш юк. Безгә аларны беркем дә каяндыр китереп бирмәячәк. Төп ышаныч – үзебездә. Булдыклы егет-кызларыбызны табып, аларны төрлечә кызыксындырып, ярдәм итеп, иңгә-иң эшләгәндә генә, авылларыбызның киләчәге булачак, – ди район башлыгы Илдар Таҗетдинов.

Район эшмәкәрләре арасында кемнәр генә юк! Хәтта чит илләрдән килүчеләр дә бар. Моның сәбәпләре турында белешә башлагач, Казаннан килеп, Мәшләк авылында үз эшен ачып җибәргән Рафаэль Гыймазов кыска гына итеп «кызыксындыра беләләр» дип җаваплады. Әйтик, җир кишәрлеге өчен түләүгә башка районнарда да ташлама каралган. Монда беренче ел өчен – тиешлесенең 20 процентын, икенче ел өчен – 40, өченче ел өчен – 60, дүртенче ел өчен 80 процентын түлисе. Биш елдан соң, аякка баскач, түләве җиңелрәк бит инде, ди Рафаэль Гыймазов.

Эшмәкәрләр фикеренчә, Балык Бистәсе районында эш башлар өчен иң уңайлы шартлар булдырылган. Ташламалы арендa хакы белән җир бирү, махсус программа нигезендә су, газ, электр уты үткәрү һәм башка эшләрдә дә һәрчак ярдәм кулы сузарга әзерләр.

– Гаилә бизнесын башлап җибәрү өчен хатыным Лилия белән Казанны гына түгел, республиканың барлык районнарын йөреп чыктык. Мәшләк авылындагы ике катлы бу бина егерме елдан артык хуҗасыз булган, тәмам җимерек хәлдә иде. Биредә яшәүчеләр аның кайчан да булса

Илдар Мөхәммәтҗанов

яңадан торгызыласына өмет өзгән була. Аны яңабаштан диярлек төзеп чыгарга туры килде, – дип искә ала ул.

Хәзер 1350 квадрат метрлы бу бинаны танырлык түгел. Якты, җылы, чиста. Биредә бүген әстерхан чикләвеге, урман чикләвеге (фундук), өрек, слива һәм тагын берничә дистә төр җимеш кушып ясалган кишер кагы җитештерә башлаганнар. Гыймазовлар янәшә авыллардан 15 кешене эшле иткән.

– Предприятие тикмәгә генә «Кишер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте дип аталмый. Безнең төп чимал – кишер. Башка төр катнашмалар да кеше организмы өчен файдалы. Витаминга бай чимал буларак, аны илнең бар почмакларында яратып алалар. Сату белән дә проблема юк. Чималны үзебездә табарга була, – ди Рафаэль Гыймазов.

Предприятие оешуның беренче көненнән башлап биредә эшләүче Рәйхана Әминова әйтүенчә, эш шартлары уңайлы, айлык хезмәт хакы да уртача 25 мең сумнан ким түгел. Төпле хезмәт хакы алгач, ипотекага торак бирү, кредит алу да җайлы. «Элегрәк, авылыбыз бетүгә таба бара, дип кайгырсак, хәзер мәктәпне тәмамлаучы егет-кызлар авылда калу ягын карый башлады», – дип шатлана биредә эшләүче Елена Кузьмина.

– Ә үзең соң, Казаннан авылга күчеп, эш башлавыңа үкенмисеңме? – дип сорыйм эшмәкәрдән.

– Өч бала үстерәбез. Үзем дә, гаиләм дә авылда эш башлавыбызга сөенеп яшибез. Киләчәккә планнарыбыз да зурдан, – ди Рафаэль Гыймазов.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ЯРДӘМ ГОМЕРНЕ САКЛЫЙ

Яшәеш

Казанның 110 нчы лицеенда тормыш иминлеге дәресе укытучысы Елена Хәлилуллина мәктәптә балаларны да, автобуста хәле китеп аңын җуйган әбине дә, поездда йөрәге туктаган ир-атны да коткарып калган. Әле болары – безгә сөйләгәне генә. Әйтми калганнары күпме!

– Битараф булырга ярамый, – ди ул. – Тик күбебезнең башкалар язмышына кайчак исе дә китми. Урамда ярдәм сораган, егылып яткан, кинәт кенә аңын җуйган кешеләргә булышырга ашыкмыйбыз. Яшерен-батырын түгел, кешеләр үзләре дә ярдәм итә белми, кемнәндер сорарга да кыюлыклары җитми. Ә бит санаулы минутлар хәл итә.

Бервакыт лицейга, тормыш иминлеге дәресләрен укырга дип, башка мәктәптән укучылар килә. Дәресләр актлар залында уза. Шунда бер малай аңын җуеп егыла.

– Баштарак берәр авыруы бардыр дип уйладым. Ул малайның, егылуга, иреннәре шәмәхәләнеп чыкты. Тизрәк күзен ачып карыйм. Алар артка киткән. Пульсы да юк. Тиз генә башкаларга әмер биреп, үзем балага ярдәм итәргә тотындым. Йөрәгенә массаж ясыйм, үзем тәрәзәне, ишекләрне ачарга, тизрәк «ашыгыч ярдәм» чакырырга дип кычкырам, – ди ул. – Бер секундны да әрәм итмичә, укучыга ясалма сулыш алдыра башладым. Бераздан ул күзләрен ачты. Менә шушы мизгелне мәңге онытасым юк. Мин аның белән тыныч кына сөйләшә башладым. Табиблар килгәч, малайның йөрәге туктап алганын әйттеләр. Баксаң, кан тамырлары белән бәйле авыруы бар икән. Йөрәк озак утырып тору аркасында да туктый ала, диделәр.

Икенче бәхетсезлек очрагы поездда була. Төн уртасы. Елена ханым бер хатынның ярдәм сорап ачыргаланып кычкырганына уянып китә.

– Тар гына вагон. Бер ирнең хәле начарайган икән. Үзем нишләргә икәнен уйлыйм, үзем тизрәк пульсын тикшерәм. Инфаркт булган очракта йөрәккә массаж ясарга ярамый. Шуңа күрә мин аңа ясалма сулыш алдыра башладым. Ниһаять, ир күзләрен ачты. Бөтен вагон миңа кул чаба. Ул төнне йоклап тормадым. Шушы вагондагы кешеләргә беренче ярдәм күрсәтү буенча мастер-класс уздырдым, – ди ул. – Бу хәлләр минем белән булмас диярга ярамый.

Автор фотосы

Һәркемнең берәр кешесенә ярдәм кирәк булырга мөмкин. Әйтик, бер елны Казанның Адоратский урамындагы тукталышта давыл чыгып, түбәдән очып төшкән калай бер егетнең аягын зарарлаган. Янындагы кешеләр берни эшли алмаган. Ул кан югалтудан үлде. Әгәр кемдер жгут салган булса, егетне коткарып калып булыр иде.

Күптән түгел Елена ханымның бер укучысы үзен үзе коткарган. «Рубин» командасы җанатары булган ул. Футболдан соң каршы як белән бәрелеш була. Менә шунда аның ботындагы артериясе өзелә. Егет югалып калмый – каешын салып, кан килүне туктата. «Әгәр шулай эшләмәгән булса, 2,5 минуттан үләр иде», – ди укытучы.

Иртән ашамау һәм гел утырып тору кешенең сәламәтлегенә зур зыян сала. Елена Хәлилулина моны үз тәҗрибәсеннән чыгып әйтә. Укучылар арасында да хәлсезләнеп китүчеләр, аңын җуючылар бар икән.

– Балалар дөрес тукланмый. Иртән ботка ашап килүчесе сирәк. Организмга зыян китерә торган ризыкларга өстенлек бирәләр. Ач кеше аңын җуя. Миңа көненә 3–4 бала ярдәм сорап керә. Сабыйлар гади генә ситуациядә дә нишләргә кирәген белми, – ди ул.

ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА КИҢӘШЛӘР

- Бер урында озак утырырга ярамый. Өйдә турник ясап куегыз. Ир-атлар вакыт булган саен шунда шөгыльләнсен. Кызларга исә вакыт-вакыт биеп алырга кирәк.
- Кан яхшы йөрсен өчен, гел хәрәкәттә булу мөһим.
- Кешенең беләзегендә пульс сизелсә, димәк, кан басымы нормаль, әгәр култык асты тирәсендә генә абайланса, төшә башлаган дигән сүз, ә пульсны муен тамырында гына сизәсез икән, бу кешегә тиз арада ярдәм кирәк, дигәнне аңлата.
- Кемгәдер ярдәм иткәндә, башкаларны әмер биреп эшләтергә кирәк.
- Урамда ярдәм кирәк кеше күрсәгез, ташлап китәргә ярамый. Хәлен сорагыз, табибларны чакырыгыз. «Ашыгыч ярдәм» чакырганда, кем икәнегезне әйтү мөһим.

Шуңа да Елена Хәлилуллина тормыш иминлеге дәресләрендә укучыларны иң элек курыкмаска өйрәтә.

– Балаларның күбесе, кан күрсә, аңын җуя. Әмма болай ярамый. Үзеңне җиңәргә кирәк. Безнең мәктәптә беренче ярдәм күрсәтү өчен бөтен кирәк-ярак, тренажерлар җитәрлек. Шуңа да эшләү җиңел. Балаларга да аңлатырга рәхәт, – ди ул. – Без дәресләрне, бармак киселгәч, нинди ярдәм кирәклеге турында аңлатудан башлыйбыз. Яраны бинт белән дөрес итеп бәйләргә өйрәтәбез. Аннары исә кечкенәрәк сыйныфларга газ шартлаганда, йортлар җимерелгәндә нишләргә кирәгенә төшендерәбез. 11 нче сыйныф укучыларын инсульт, инфаркт, йөрәк өянәге булганда ярдәм итәргә өйрәтәбез. Соңгы елларда балаларга мәктәпкә һөҗүм итү очраклары булганда нишләргә кирәклеген дә яхшылап аңлатабыз. Куркыныч хәлләр вакытында укучылар үзләрен ничек тотарга кирәген белми. Әти-әниләр дә сабыйларга бу хакта сөйләсә иде.

Кешене тормышка кайтару өчен төп күнегү – йөрәгенә массаж ясау (30 тапкыр басу) һәм ике тапкыр ясалма сулыш бирү. Моны дөрес итеп эшләргә кирәк. Әгәр йөрәккә катырак яки күбрәк бассаң, күкрәк читлегенә зыян килергә мөмкин. Шуңа күрә 30га кадәр кычкырып санарга кирәк. Кеше үз косыгы белән тончыкмасын өчен, авыз куышлыгын тикшереп торыгыз. Бу күнегүләрне кеше сулый башлаганчы йә «ашыгыч ярдәм» машинасы килгәнче кабатларга кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

МОРТАЗИН АБДРӘХИМ МОРТАЗА УЛЫ

(21.08.1927–05.12.2021)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Элекке КПСС Биектау районы комитеты беренче секретаре, Бөек Ватан сугышы ветераны Мортазин Абдрәхим Мортаза улы 5 декабрь көнне 95 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Абдрәхим Мортазин 1927 елның 21 августында ТАССРның Арча кантоны Мүлмә авылында дөньяга килә. 14 яшендә Биектау районының Ворошилов исемендәге колхозда эшли башлый.

1944 елда армия сафларына чакырылып, 1954 елның апреленә кадәр Төньяк флотта хезмәт итә. Сугыш вакытында илебезгә диңгез аша хәрби техника, корал, азык-төлек ташучы хәрби корабларны озатып йөрүдә, аларны Баренц диңгезе аша хәвеф-хәтәрсез уздырып җибәрүдә катнаша.

Абдрәхим Мортазин хәрби уңышлары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм «Германияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнә, «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медаленә лаек була.

Хәрби хезмәттән кайткач, Биектау районының комсомол һәм партия органнарында эшли. 1960 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы Казан югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң Биектау район комитеты икенче секретаре вазыйфасына сайлана, шуннан соң район советы башкарма комитетына җитәкчелек итә. 1962 елда Яшел Үзән районына партия эшенә күчерелә.

1965 елда Абдрәхим Мортазин КПССның Биектау районы комитеты беренче секретаре итеп сайланып, 23 ел дәвамында шушы вазыйфада хезмәт куйды. Аның җитәкчелегендә Биектау районында социаль-мәдәни өлкә, сәнәгать актив төстә үсте, авыл хуҗалыгы объектлары төзелде, торак пунктлар төзекләндерелде. Күп кенә колхоз-совхозларда терлекчелек комплекслары, механика остаханәләре, печән саклагычлар пәйда булды. Районда тәүге «Шәпше» агрошәһәрчеге төзелде, «Юбилейный» торак бистәсе пәйда булды, яңа мәктәпләр һәм мәдәният йортлары ачылды.

Абдрәхим Мортазин 1988 елда Казан оптика-механика заводы генераль директорының авыл хуҗалыгы производствосы буенча ярдәмчесе итеп билгеләнде. Шуннан лаеклы ялга чыкты.

Абдрәхим Мортазинның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Почет билгесе», «Халыклар дуслыгы» орденнары, «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның меңьеллыгы истәлегенә» Татарстан Республикасы медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы.

Тормышта актив позициядә торуы, зур оештыру сәләтенә ия булуы һәм эшлеклелеге аңа эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә уңышка ирешү мөмкинлеге бирде.

Абдрәхим Мортаза улы кайда гына эшләмәсен, үзен һәрвакыт белемле, гадел һәм җаваплы җитәкче буларак танытты. Кешеләргә карата ихтирамлы мөгамәләсе, актив иҗтимагый эшчәнлеге аңа зур абруй-хөрмәт һәм танылу китерде.

Мортазин Абдрәхим Мортаза улының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин,
А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, М.А.Җәббаров, Ә.С.Гобәйдуллин,
Р.Ф.Хисаметдинов, Х.Г.Иштирәков

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, элекке КПСС Биектау районы комитеты беренче секретаре (1965–1988 елларда)

МОРТАЗИН Абдрәхим Мортаза улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» тагын бер җиңү яулады

Редакциябез сайты «Белем җәүһәрләре» татар интернет-проектлары бәйгесенең «Гаилә, милли тәрбия һәм сәламәт яшәү рәвеше өлкәләрендә иң файдалы һәм популяр интернет-проект» номинациясендә беренче булды.

«Белем җәүһәрләре» бәйгесен Татнетны үстерү фонды Татарстанның Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыклары белән берлектә, күп санлы иганәчеләр ярдәме белән 12 нче тапкыр уздырды. Бәйгедә катнашучылар саны быел ике йөздән артып киткән, ә финалга «иң-иң»нәрдән саналган 53 катнашучы гына уза алган.

Татнетны үстерү фонды җитәкче Раил Гатауллин әйтүенчә, татар телле интернет-ресурслар елдан-ел арта, сыйфатлары яхшырганнан-яхшыра.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева сүзләренчә, әлеге бәйгегә күбрәк татар телле яшьләрне җәлеп итәргә кирәк. «Интернет шартларында үз урыныңны яулау ул – бик четерекле эш. Монда һәр кешенең, оешманың тырышлыгы бәясез. Миңа калса, киләчәктә яшьләрне тагын да активрак катнаштыру бурычы алда тора», – диде ул.

ГИМН ХАЛЫКНЫҢ КОДРӘТЕН КҮРСӘТӘ

ВЕТЕРАН ЖУРНАЛИСТ 80ләп ИЛНЕҢ ГИМНЫН ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘ ИТКӘН

Кызык кеше

Чаллыда яшәүче ветеран журналист Фәһим Җиһаншин укучыларыбызга таныш инде. Ул үз теләге белән дөньяда иң зур халыкара сүзлекләрнең берсе – tt.forvo.com сайтында татар тупланмасын алып бара. Фәһим ҖИҺАНШИНның кайберәүләргә гайре табигый булып тоелган, үзе әйтмешли, бушка эшләнә торган, «файдасы-кирәге булмаган» шөгыльләре тагын да бар әле. Мәсәлән, ул төрле илләрнең гимннарын татар теленә тәрҗемә итә. Хәзер аның коллекциясендә 80ләп илнең гимны бар.

:: Фәһим абый, сез ничек уйлыйсыз: гимннар ни өчен кирәк?

– Күп кенә халыкара спорт ярышларында, җиңүчеләрне зурлап, ни Россия гимны уйналмый – «санкцияле» дәүләтнеке булганга, ни Татарстанныкы – рәсми һәм бәйсез түгел… Гимн бит ул халыкның рухи яктан ни дәрәҗәдә бай булуын, кодрәтен күрсәтә. Әллә безне, шуннан мәхрүм итеп, сындырмакчы булалармы? Халык ни белән яши, нинди кыйммәтләре бар, нәрсәгә омтыла – гимнда бу сорауларның барысына да җавап табылырга тиеш. Кыскасы, бу символ бик зур әһәмияткә ия: ахыр чиктә гимннары нинди – иле, халкы шундый булып чыга. Алар бик төрле. Темпераментлы, моңсу, тантаналы, уйчан гимннар бар. Сүзләре белән көйнең дә тәңгәл килүе кирәк.

:: Мондый баш җитмәслек эш белән шөгыльләнүегез нидән башланды?

– 1993 ел иде бу. Бәйрәм күрергә дип, Чаллыдагы Сабантуй мәйданына чыктым. Сәхнәдән Нәсимә исемле бер җырчы, үзәкләрне өздереп, татарча җырлый. Ирексездән туктап калдым. Тыңлый торгач, исемә төште: бу җырны бит башта Татарстан гимны итеп тәкъдим иткәннәр иде. Аннан Рөстәм Яхин көен сайладылар, ә Рамазан ага Байтимеровның «Туган ягым» шигыре… гимн тексты була алмый, диделәр. Гимн сүзсез килеш тагын 19 ел яшәде. Уйланып йөри торгач, ирексездән, күңелемдә фикерләр тупланды, берәр текст язып карыйсы килде. Тик бу уем тиз генә тормышка ашмады әле. Бернинди фикергә дә килә алмыйча, төрле илләрнең гимннарын өйрәнә һәм тәрҗемә итә башладым.

:: Бу шөгыль тагын нәрсәсе белән җәлеп итте?

– Мин башкалар кулы тимәгән өлкәләрдә казынырга яратам. Әле журналист булып эшли башлаган чагым гына иде. Бер танышым миңа: «Башкалар бармаган җиргә бар, кеше язмаганны яз», – дип киңәш биргән иде. Башта аның сүзләрен тыңладым. Тора-бара үзем дә күнеп киттем. Мин юләрдән башка кем гимннар тәрҗемә итеп утырсын инде бу «ашкынып куллану заманы»нда? Ни калҗасы, ни акчасы дигәндәй. Ә миңа бу шөгыль рухи ләззәт бирә. Бик авыр булып киткән мизгелләрдә кайсыдыр гимнның сүзләре искә төшә, шундук ниндидер көч, ышаныч пәйда була. Җитдирәк әйткәндә, гимннарны өйрәнү күп нәрсә бирә ул. Бер яктан, башка халыкларның тормышы, гореф-гадәтләре, тойгы-хисләре белән якыннанрак танышасың, икенчедән, тәрҗемә итү барышында туган телебезнең һәм башка телләрнең нечкәлекләренә ныграк төшенәсең.

:: Тел дигәннән, сез ничәне беләсез соң? Сиксән бик күп бит ул.

– Бер генә чит ил телен дә актив кулланмыйм. Гомер буе моңа стимул һәм ихтыяҗ булмады. Барысы да хәтернең «пассивлык капчыгы»нда. Алман һәм инглиз телләрендәге язмаларны еллар буе укып киләм анысы. Байтак телнең фонетикасын, грамматикасын истә калдырдым. Белмәгән сүзләрне тәрҗемә итү өчен сүзлекләрдән файдаланам. Татарга тылмач кирәкми: сөйләшмәсәм дә, күп телләрне аңлый башладым. Мәсәлән, миңа мәҗар (венгр) теле ошый. Ул бик катлаулы, аны өйрәнергә көчем җитми инде. Шулай да, энә белән кое казый-казый, мәҗар телендәге ике гимнны тәрҗемә иттем. Мәҗарлар бүгенге биләмәләренә төпләнгәнче, төрле халыклар белән элемтәдә булганнар. Аларда фарсы, немец, славян, төрки телләр сүзләре бик күп. Тел белгечләре әйтүенчә, венгрлар Идел буе татарлары теленнән үзләштергән яки ике халык өчен борынгыдан ук уртак булган 800дән артык сүз бар.

ak-bars.ru

:: Гимннарны татар теленә тәрҗемә итү авырмы?

– Җиңел дип әйтеп булмый. Монда юлын юлга тәрҗемә итү турында сүз бармый бит. Башта сүзлек юнәтәм. Аннан ул телнең грамматикасын, бигрәк тә исем белән фигыльләрнең төрләнешен өйрәнәм. Телләр төрледән-төрле бит. Мәсәлән, татар теле фигыльләргә нигезләнгән, ә немец теле – исемнәргә. Җөмлә төзелешенә, фикер сөрешенә төшенү дә кирәк. Барлык гимннарны тәрҗемә итеп тә булмый. Ритм белән рифманы да саклыйсы, халыкның рухиятен дә чагылдырасы бит.

:: Сезнең карашка, кайсы илнең гимны иң уңышлысы?

– Казахстанныкы дип уйлыйм. Аның тексты – милли идеяләр җыелмасы. Шулар ярдәмендә беренче президент Нурсолтан Назарбаев халыкны алга өндәде. Якынрак күршеләребезнекенә килсәк, удмурт гимнын уңышлы дип саныйм. Аның сүзләре символик әһәмияткә ия, мәгънәсе тирән. Беренче куплетында төп сүз – миләш, икенчесендә – торналар. Миләш – Ижау шәһәренең символы, ә торна – удмуртларның милли кошы (татарларның сандугачы булган кебек). Музыкалары да удмуртча, килешеп тора. Әйтергә кирәк, совет хакимияте урнаштырылганнан соң, Идел буе халыклары арасында иң беренче гимнны чуашлар язган.

:: Яраткан гимныгыз бармы?

– Андыйлар байтак. Бигрәк тә Латин Америкасы илләренекен яратам. Күбесен үз телләрендә җырларга да өйрәндем. Әле берсен, әле икенчесен көйләп йөрим. Кайберләре, салмаграклары, кече оныгымны йоклатканда, бишек җыры булып та хезмәт итә.

:: Һәр гимнның үз тарихы бардыр? Иң кызыклысы?

– Финнарныкын әйтеп китәргә мөмкин. XIX гасыр уртасында шведлар, ил халкының 10 процентын гына тәшкил итсәләр дә, дәүләт белән идарә иткәннәр. Гимнны да алар язган. Финнар аны үз телләренә бары тик 41 елдан соң гына тәрҗемә итә алганнар. Күп кенә илләрнең гимннары бик үзенчәлекле халәте белән мавыктыргыч. Әйтик, Швейцариянең 180 еллык гимны… әле бүген дә рәсмиләштерелмәгән килеш кулланышта. Канада гимнын француз һәм инглиз телендә җырлыйлар, һәрберсе үз телендә башкара, текстлары тәңгәл килми. Императорларга теләк-мөрәҗәгать рәвешендәге Японияненеке бары тик 32 иҗектән һәм 18 сүздән тора. Аны тыңласаң, дога укыган кебек хис кала. Австрия гимнын Моцарт музыкасына… тамырлары хорват милләтеннән булган шагыйрә язган.

:: Гимннар еш алышынамы?

– Төрлесе бар, шул исәптән бик еш алышынганнары да. Мәсәлән, Иран. Соңгы 100 ел эчендә ул гимнын 4–5 тапкыр алыштырган. Яңа хаким килү белән символлар да яңара икән бу илдә. Бүгенгесе дини темага язылган. Патша Россиясе чорында да гимн бик еш алышынган. Кайбер илләрдә, мәсәлән, Таиландта һәм Скандинавия илләрендә икешәр гимн гамәлдә – корольнеке һәм дәүләт белән милләтнеке аерым.

:: Бу эшнең башка төрле файдасы да юк түгелме?

– Кешеләр, олыгайгач, баш миләре эшләүдән туктамасын өчен, кроссворд чишәләр, шашка-шахмат уйныйлар. Ә мин гимннарны һәм… Игорь Губерман «гарик»ларын тәрҗемә итү белән шөгыльләнәм (боларның 550сен Википедиягә урнаштырдым инде). Димәк, сәламәтлегемне дә бераз саклыйм булып чыга. Җитдирәк әйтсәк, икесен дә халыкка тәкъдим итү мөмкинлеге табылса, бик шат булыр идем. Кызыксынучылар булыр дип уйлыйм. Татарның «фикерләү диапазоны»н киңрәк җәелдерсәк, комачауламас иде.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН ГИМННАР ТЕКСТЛАРЫ VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Спорт

Барысы да элеккечә

Көрәш буенча Россия чемпионатында 10 алтынның 7сен Татарстан көрәшчеләре яулады. Чемпионнар киләсе елда дөнья чемпионатында чыгыш ясаячак.

tatarstan.ru

Идел буе физик культура, спорт һәм туризм университеты келәмендә ярыш башланганчы, илкүләм федерациянең хисап-сайлау җыенын уздырдылар. Төп яңалык – федерация президенты итеп киләсе 4 елга янә Җәүдәт Миңнәхмәтовны сайладылар. Ул әлеге вазыйфаны инде 2006 елдан бирле башкара.

Россия чемпионатында исә 31 төбәктән 140 көрәшче бил алышты. Баштарак ике көн узар дип фаразланган ярышны шимбә кичендә үк тәмамладылар. Аңлашыла инде, келәмдә төп фаворит булып Татарстан егетләре саналды. Нәтиҗәдә безнекеләр 10 үлчәү категориясенең 7сендә батыр булып танылды. Ике алтын медальне Башкортстан егетләре яулады.

60 килолы егетләр ярышының финалында Алексеевскидан Алексей Абрамов Төмән егете Мурадали Мурадовка бер мөмкинлек тә калдырмады. 65 килолылар бәйгесендә Балтачтан Илназ Миңмуллин Ульян егете Артур Хәкимовтан өстен чыкты. 70тә Алабуга батыры Ислам Фәлахов Санкт-Петербургтан Эмиль Җиһаншинны отты. Ә менә 75 килолы егетләр ярышында Менделеевск районыннан Рафаэль Кәлимуллин Башкортстаннан тәҗрибәле Артур Зөлкәрнәевкә каршы тора алмады. Аның каравы Рафаэльнең абыйсы Ренас 80леләрдә Ханты-Манси округыннан килгән Игорь Волобуевка бер балл да бирмәде.

Финал алышларының иң кискене 85 килолы егетләр очрашуында булды. Кукмарадан Раил Сәлахетдинов белән Башкортстаннан Дим Хәйруллин бик озак тартыштылар. Алыш кунак егетнең өч кисәтү алып җиңелүе белән тәмамланды. 90 килолы чемпион исемен Казаннан Илмир Төхвәтуллин яулады. 100 килолы егетләр бәйгесенең финалында исә Башкортстаннан ике егет бил алышты. Айнур Сыртаев чемпион булды. Балтачтан Руслан Рәфыйков өченче урынны алды.

Авырлыгы 130 килодан артмаган егетләр ярышын Зәйдә туып, Әлмәт өчен бил алышучы Радик Сәлахов отты. Финалда ул Ханты-Манси округыннан Таһир Зөлкәрнәевне җиңде. Иң авыр көрәшчеләр арасында исә Сергей Павликны ега алучылар бу юлы да табылмады. Мәскәү һәм Калуга өлкәләре өчен бил алышкан Ульян пәһлеваны чемпион исемен яулады, Яшел Үзәннән Фирдүс Зәйнуллин исә икенче булды.

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә — ~~465 сум~~ **404,04 сум**

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә — ~~1000,92 сум~~ **859,08 сум**

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

ДЕКАБРЬ «АЛМАЧУАР»Ы

Премьера

Әтнә театры башкалардан кай ягы белән аерылып тора? Бу сорауны аның премьераларында булган һәр кеше үз-үзенә биргә торгандыр. Чыннан да, алар үзгә бит. «Алмачуар» спектакленнән соң аңлашылды: аларның үзгәлекләре табигать балалары булуларында икән.

atnyateatr.ru

Табигыйлык, чыннан да, сагындырган. Әтнәлеләр шуңа күрә яраттыра, кимчелекләренә күз йомдыра да инде.

Декабрь аенда театрга килеп, печән исен иснәүләре генә дә ни тора! Хуш исле печән тамашачыны авылга, үткәненә, балачагына кайтып килергә беренче мизгелендә үк әзерләде. Моңа Мәскәү тәнкыйтьчеләре дә игътибар иткән. Печән күргән бар, мондый хуш ислене юк, ди ГлебСитковский да:

– Кечкенә генә авылның кечкенә генә театры үзенчәлекле алым алып килде! Авыл манзарасы, печән исе, залга үтүгә үк, мөгаен, ниндидер могҗиза булыр дип көттерә башлый. Ә бит театр беркайчан та табигать турында була алмый. Ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, интеллектуаль уеннар турында булырга мөмкин. Әмма сәхнәдә табигатьне беркайчан да тулы канлы итеп сурәтләп булмый. Аның мөмкинлекләре аз. Ә бүген, теләгәндә, мөмкинлекләрне булдырып булганлыгын күрсәттеләр. Әлбәттә, куелышта техник кимчелекләр шактый булса да.

Спектакль печәне белән генә түгел, авыш яссылыкта булуы белән дә үзенчәлекле. Актерларга буеннан-буена печән җәелгән калкулыкта уйнарга туры килде. Бик кызык чишелеш. Кайдадыр тау астындагы Сабантуйга да, малайларның су коенганына да, ат чабышы барганына да ышанып утырасың. Теге хуш исле печән биш минуттан аска коелып бетә, билгеле… Анысы инде икенче мәсьәлә.

Тамашачыга вакыйгаларның ни турында барганын Закир карт (Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин) аңлата. «Сабан туенда әти башкортка җиңелгәч башланды инде безнең гаилә кайгылары», – дип, балачагына алып кайта. Аның янәшәсендә кечкенә Закир (Раил Сәлахиев) пәйда була.

Малай Закир ул елларның афәтләренә бик тирән төшмичә генә абыйсын 20 елга каторгага хөкем итүләре, апасының авыр вакытта гармунчыга ябышып чыгуы турында әйтеп уза. Ул әйтеп уза да Зөһрә Мөхәммәтгалиева, Фаяз Хөсәенов иҗат иткән кызыклы образлар шуның белән гаип була. Мөхәммәтхафиз образы да (Айдар Вәлиев) ниндидер тонык, кирәк булганга гына йөри дигән тәэсир кала. Бу, бер караганда, табигый да. Ник дигәндә, үзәктә – малай белән Алмачуар мөнәсәбәте. Спектакль дә бит бер мәхәббәт тарихы дип тәкъдим ителә.

> Алмачуар җан биргәндә, мин аның баш очында идем. Елый алмадым, йөрәгем таш булып катты. Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым. Алмачуар минем йөрәгемдә: җиргә, күккә, адәмнәргә, бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.

Колын образында – Алинә Сидеева. Ак күлмәкле, озын чәчле гап-гади кыз. Тик ул колынның тугач аякланып китүен шундый осталык белән башкара ки, колын булса, шундый булсын, дигән уеңнан үзең үк елмаясың.

Спектакль иллюстратив, сүз дә юк. Театр тәнкыйтьчесе Владислава Куприна әнә шундый фикердә. Ул постановканың ирониягә бай булуын, артистларның харизмасын, режиссер Айдар Җаббаровның байтак алымнарын билгеләп үтте.

«Пушкин картасы» программасына бер дигән әсәр булган, билгеле. Спектакльдәге вакыйгаларның кайсы елларда барганлыгын гына аныклыйсы бар. Мәгълүм булганча, әсәр 1922 елда язылган. Ә спектакль безнең көннәрдә Сабан туе мәйданында башланып китә. Кунак агач төбенә хәмер эчәргә чүгәли, мәхәббәтенә хыянәт иткән Закир кеше артыннан чүп җыеп йөри. Мәхәббәтенә хыянәт иткәнгә, тормышы барып чыкмаган, күрәсең… Артистларның киемнәре дә тамашачыны ялгыштыра. Мәсәлән, Закирның әнисе, хәзерге заман ханымнары кебек, башына «чалма» ураган, камзул белән ефәк күлмәк кигән. Ул чорда авыл хатыны, ай-һай, алай киендеме икән?.. Классик әсәр әзерлекле булуны таләп итә шул.

Сүз уңаеннан, спектакль «Һөнәр» фестивале кысасында күрсәтелде. Әлеге чарада театр тәнкыйтьчеләре арасында үзебезнекеләрдән Нияз Игъламов, Айрат Бик-Булатов күренде. Рауза Солтанова, Айгөл Габәши тамашачы сыйфатында карадылар. Татар әдәбиятын белгән белгечләр бу җәһәттән театрларга киңәшләре белән күбрәк ярдәм итә алыр иде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КУЛЫМДАГЫ ЙӨЗЕГЕМНЕҢ ИСЕМНӘРЕ... ЗАКАЗГА

Кукмара районының Купка авылы егете Айнур Ибраһимов күптән түгел үзенең зәркән остаханәсен ачкан. Казанда яшәп, авылга кайткан егет белән халыкның зәвыгы, зәркәнчелек турында сөйләштек.

Айнур эшләгән остаханәнең ишеген кемнәр генә шакымый! «Улым, менә бу борынгы йөзегемне заманчалаштырып үзгәртеп бирмәссеңме икән», – дигән әбиләр дә, үзенчәлекле әйберләр кияргә яраткан кызлар, матурлык турында онытмаган ханымнар да бар. «Борынгы булса да, заман дизайнына туры килә», – дип, сирәк очрый торган затлы алка яки балдакны әрәм итмәскә үгетләгән чаклары да була аның. 17 ел тәҗрибәсе булган зәркәнче, кешеләрнең йөзенә карауга ук, бусагадан атлаучының таләбен чамалый. Әлбәттә, бу эштә төгәллек кирәк. Әгәр бер әйберне җиренә җиткереп башкарсаң, сиңа, һичшиксез, икенчесен, өченчесен дә китерәчәкләр. Менә шул ышанычны аклаганга күрә, үз остаханәсен ача алган да инде ул.

Казанның 40 нчы һөнәр училищесында рәссам-бизәүче һөнәрен үзләштергәч, берничә ел ремонт эшләре белән шөгыльләнгән, аннан үз бизнесын булдырган. Дөресен генә әйткәндә, кайчан да булса, зәркәнче булып китәрмен дип башына да китермәгән. Нәселендә оста куллы кешеләр күп, әмма алтын-көмеш белән эш итүчеләр юк. Бу урында Айнур, елмаеп кына, бер вакыйганы искә төшерә. Училищеда укыганда сабакташы аңа: «Сиңа зәркәнче булырга кирәк», – ди. Моңа әллә ни игътибар итмәсә дә, бер-ике елдан беренче йөзеген ясагач, шул кызның сүзләре искә төшә. Егетнең мәхәббәттән янып йөргән чаклары. Бу вакытта ике йөрәк төшкән көмеш йөзекнең иясе билгеле була инде.

Айнурның күңеленә күбрәк көмеш эшләнмәләр якынрак. Бу аңа эчке халәтен ачарга, чынга ашмаган хыялларын тормышка ашырырга ярдәм итә. «Зәркәнче эше аша дөньяны таныйм, күңелгә ниндидер мәгънә алам. Мине зәркәнчелеккә табигать өйрәтте. Табигатьтән бик күп нәрсәгә өйрәнергә була», – ди әңгәмәдәшем. Аңың әйтүенчә, яхшы зәркәнче булу өчен, рәссамча караш, иҗади фикер йөртү, кешенең зәвыгын тоемлый белү кебек сыйфатлар кирәк.

– Замана хатын-кызларын нинди зәркән эшләнмәләре кызыксындыра? – дип сорыйм Айнурдан.

– Нәфислек ул – һәр хатын-кызга хас әйбер. Ул аңа омтылды, омтыла һәм омтылачак. Шәһәр кешесе – үзенчә, авылныкы – үзенчә. Тик авыл һәм шәһәр дип аерып булмый. Бүген интернет заманында боларның чикләре юкка чыгып килә. Авыл өчен зәркәнчелек ят күренеш түгел. Элек тә зәркән эшләнмәләренә сорау булган. Бүген дә ул үз урынын югалтмый һәм югалтмаячак. Кибеттә нәрсә модада – бездә дә шуңа ихтыяҗ бар. Мода бүген – бер, иртәгә икенче төрле. Үзгәреп тора бит ул. Берәүләр – бик гади, икенчеләр кысага сыймаслык эшләнмәләр ясатырга мөмкин. Шулай да вак ташлар белән ясалган зәвыклы әйберләргә ихтыяҗ күбрәк. Күпләр ялтыравыкка, алтынга кызыгалар. Кабатланмаган шедеврлар сораучылар, сәнгатьчә караучылар сирәк. Алар модага иярми, андыйларның – үз карашы. Заказга күбрәк кул эшен аңлаучы һәм аңа бәя бирүчеләр бирә. Кулдан ясалган иҗат эше беркайчан да кабатланмый, шунлыктан кадерлерәк һәм югары бәяләнә, – ди Айнур.

Айнур Ибраһимовның шәхси архивыннан

– Вак эш бит, туйдырмыймы, моның өчен сабырлык та кирәк, – дип кылларын тарткалыйм останың. Ул исә мактануны түгел, тыйнаклыкны сайлый. «Сәгать ремонтлаучыларныкы тагын да авыррак әле. Вак эшкә дә, зурысына да түземлек кирәк», – ди. Ул күбрәк балдак, алка, брошьлар ясау белән мәшгуль. Гадәттә, бер йөзекне 3–4 көн эшли. Вак ташлар белән бизәгәндә катлаулырак, ди.

Айнур зәркәнче эшен табышлы дип саный. Әлбәттә, шәһәрдә акча эшләү мөмкинлеге күбрәк. «Күпләрне сөендердем. Менә моны табыш дип әйтеп буламы? Бу табыш була икән, калганы да була, – ди туган якларына әйләнеп кайткан Айнур. – Без эшкә хәзер барыбыз да табыш күләме аша карыйбыз. Тормышның мәгънәсен шуннан күрәбез. Очсызлы, сыйфатсыз товар җитештереп, табыш әйләнешен арттырырга тырышабыз. Шуның аркасында үзебез үк сыйфатсыз эшләргә юлыгабыз. Тик зәркәнче эшендә кешене алдап булмый. Аның өметен акларга кирәк. Үзеңә ошаса, башкаларга да ошаячак».

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 378

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+